# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ӘСӘРЛӘРЕН ТӨРЕК ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТКӘНДӘ КИЛЕП ТУГАН КЫЕНЛЫКЛАР («АЛМАЧУАР» ӘСӘРЕ ҮРНӘГЕНДӘ)

**Чулпан Зарипова-Четин,**
Кавказ университеты,
Төркия, 36000, Карс/ Мәркәз,
chulpancetin@gmail.com

**Раушания Сәгъдәтҗан кызы Нурмөхәммәтова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
rsagadat@yandex.ru

Тәрҗемә практикасында кардәш һәм кардәш булмаган телләр арасында башкарылган тәрҗемәләрне аерып карыйлар. Халыклар элек-электән бер-берсенең тарихы, мәдәнияте, әдәбияты белән кызыксынган. Шул рәвешле төрле тәрҗемәләр, башка авторларга ияреп язулар барлыкка килгән.

Тәкъдим ителә торган мәкаләнең үзәгенә кардәш төрки телләр – татар һәм төрек телләре куела. Бу телләрнең лексикасы, грамматикасы шактый охшаш булуга карамастан, тәрҗемә вакытында күп кенә кыенлыклар туа.

Әлеге хезмәт татар һәм төрек телләре арасында тәрҗемә процессында туган кайбер катлаулы очракларны бәян итүгә багышлана. Төп нөсхә белән тәрҗемә әсәрен чагыштырып анализлау хәтта кардәш телләр арасында да тәрҗемә кыенлыклары шактый очравын тагын бер кат дәлилли. Лингвомәдәни күренешләр, реалияләр, мәкаль-әйтемнәр һ.б. тәрҗемәсе шактый проблемалар тудыра. Боларны уңышлы хәл итү юллары тәрҗемәченең төрле алым-ысулларны урынлы куллана алуына бәйле. Авторлар Г. Ибраһимовның төрек теленә тәрҗемә итү өчен алынган «Алмачуар» әсәрендә сурәтләнгән татар халкының тормыш-көнкүреш үзенчәлекләрен, Сабантуй бәйрәме күренешләрен, аерым лексик берәмлекләрне бер телдән икенче телгә күчерү вакытында туган тәрҗемә трансформацияләрен җентекләп тасвирлый. Шул рәвешле кардәш телләр тәрҗемәсе турында фәнни-гамәли күзаллау барлыкка китерелә.

**Төп төшенчәләр:** кардәш телләр, татар теле, төрек теле, тәрҗемә, тәрҗемә кыенлыклары, тәрҗемә эквивалентлары, тәрҗемә трансформацияләре

## Кереш

XX-XXI йөзләр чигендә татар әдәбиятын тәрҗемә итүдә яңа чор башлана. Татарстан Республикасы суверенитетының беренче елларында ук төрки дөнья белән мәдәни һәм гуманитар элемтәләр киңәя. Төрек әдәбияты тәрҗемәләре белән бер үк вакытта татар поэзиясе һәм прозасының төрек теленә тәрҗемәләре дөнья күрә. Әлеге эшләр, нигездә, Чулпан Зарипова-Четин һәм Фатих Котлы исемнәре белән бәйле. Аяз Гыйләҗевнең Фатих Котлы тәрҗемә иткән «Өч аршин җир» повесте Төркиядә югары әдәби бүләк белән билгеләп үтелә [1]. Төрек теленә тәрҗемә ителгән татар әдәбияты әсәрләре арасында Ринат Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романының Мостафа Өнәр ясаган тәрҗемәсен [2]; Аяз Гыйләҗевнең Фатих Котлы тәрҗемә иткән «Җомга көн кич белән» [3], «Өч аршин җир» повестьларын; Әмирхан Еникинең «Матурлык», «Әйтелмәгән васыять» әсәрләрен [4], Рабит Батулланың [5], Ркаил Зәйдулланың хикәяләрен [6], Фатих Әмирханның «Сәмигулла абзый», Галимҗан Ибраһимовның «Табигать балалары», Фәрит Яхиннның «Ак әбиләр догасы» һ.б. татар прозасының классик үрнәкләрен атап үтәргә була [7, 447 б.]. 2008–2020 еллар арасында Төркиядә Чулпан Зарипова-Четин һәм Хаяти Йылмаз тарафыннан Гаяз Исхакыйның «Көтелгән бикәч», «Сөннәтче бабай», «Остазбикә», «Кәҗүл читек», «Кияү» һәм «Елавык Хәйрулла» кебек хикәя һәм повестьлары [8], Марсель Гариповның «Мәңгелек мәхәббәт» романы [9], Чулпан Зарипова-Четин тарафыннан Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» повесте [10] тәрҗемә ителә. 2019–2023 еллар арасында Гөлшах Йылмаз тарафыннан Роза Туфитуллованың «Гөлсем» [11], Бүләнт Бәйрәм һәм Дуйгу Дуди Эртем тарафыннан Фәүзия

Бәйрәмованың «Чыңгыз Айтматовның татар анасы» [12], Альп Эрен Демиркая тарафыннан Әлфия Ситдыйкованың «Дөнья тәгәрмәче» [13] әсәрләре тәрҗемә ителде.

Татар әдәбиятының җәүһәрләрен төрек теленә тәрҗемә иткәндә, максат бары тик бер татар язучысын һәм аның әдәби әсәрен таныту гына түгел, ә бәлки әдәби әсәр үрнәгендә татар халкын, аның тормыш рәвешен, яшәү фәлсәфәсен һәм милли кыйммәтләрен күрсәтү дә булырга тиеш. Шуңа күрә халкыбызның көндәлек тормышы, гасырлар буе яшәп килгән гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре тасвирланган һәм татар халкының тел үзенчәлекләре ачык чагылыш тапкан, әсәрләрендә мәкаль-әйтемнәрне, үзенчәлекле чагыштыруларны мулдан кулланган язучыларның хикәя һәм романнарына мөрәҗәгать итү дөрес булыр. Нәкъ менә шуны күз алдында тотып булса кирәк, төрек теленә тәрҗемә итү өчен тәрҗемәчеләр бигрәк тә Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев кебек татар халык тормышының энциклопедиясен язып танылган язучыларыбызның әдәби мирасына мөрәҗәгать итәләр дә инде.

Татар әдәбияты классигы, язучы, әдәбият һәм тел белгече, публицист, тәнкыйтьче, тарихчы, җәмәгать һәм сәясәт-дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның хикәя һәм повестьлары да нәкъ менә югарыда телгә алынган үзенчәлекләре белән игътибарны җәлеп итә. Чөнки Галимҗан Ибраһимов барыннан да бигрәк «үз халкының күңел хәрәкәтләрен, аның “яхшылык” һәм “яманлык” турындагы төшенчәләрен, идеалын һәм фольклорын аңларга тырышып язды» [14, 9 б.].

2022 елда Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар», «Көтүчеләр» һәм «Татар хатыны ниләр күрми» дигән өч әсәре галимә Чулпан Зарипова-Четин тарафыннан төрек теленә тәрҗемә ителеп, Төркия башкаласы Әнкарада Евразия Язучылар Берлеге нәшрияты булган «Бәнгү нәшрият йорты»нда аерым китап булып басылып чыкты [15]. Тәрҗемәче Г. Ибраһимовның бу әсәрләрен сайлаганда да, аларның халкыбызның гореф-гадәтләренә, бәйрәмнәренә һәм халыкның күмәк акылы тудырган халык авыз иҗатына бай булуын күз алдында тотты. Чөнки фольклор һәрбер халыкның мәдәни байлыгын һәм милли традицияләрен, ягъни әдәби һәм тарихи мирасын чагылдыра.

Мәшһүр рус галиме П. Коган юкка гына Г. Ибраһимовның «Алмачуар» әсәрен «нәсер сәнгатенең җәүһәре» дип атамый [16, 37 б.]. Галим М. Хәсәнов та «Алмачуар» повестен татар әдәбиятының үсешенә, психологик яктан тирәнәюенә, тасвирлау чараларының баюына һәм камилләшүенә зур йогынты ясаган классик әсәр дип билгели [17, 190 б.].

«Алмачуар» повестенда бөтен төрки халыклар өчен уртак тема – атка булган мәхәббәт яктыртыла. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: татарларда атка мөнәсәбәт халык авыз иҗаты җәүһәрләрендә аеруча ачык чагыла. Мисал өчен, ат турында 600 гә якын мәкаль һәм әйтем сакланган. Әкият һәм дастаннарда да ат – кешенең тугрылыклы юлдашы, иң авыр вакытта ярдәмгә килә торган дусты буларак бирелә. Татар халкында ат турында бик матур һәм мәгънәле җырлар, кызыклы ырымнар һәм ышанулар да бар [18, 134 б.].

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Бу хезмәттә сүз Г. Ибраһимовның «Алмачуар» повестен төрек теленә тәрҗемә итү барышында очраган кыенлыклар һәм аларны хәл итү турында барачак. Әлбәттә, фәнни әдәбиятта татар классик шагыйрьләре һәм язучылары иҗатын төрек телле укучыларга җиткерү тарихы, әдәби тәрҗемә вакытында килеп туган үзенчәлекләр турында хезмәтләр күп булмаса да, очрап тора (*Кар.*: [19], [20], [21], [22], [23], [24], [25], [26]). Аерым алганда, Э. Хәбибуллинаның «Татар әдәбиятын төрек теленә тәрҗемә иткәндә тел трансформацияләре» дигән темага диссертациясен атап үтү урынлы булыр [21]. Биредә автор тәрҗемә вакытында барлыкка килгән лексик-грамматик трансформацияләр турында шактый җентекләп яза, ике кардәш тел арасында булган охшаш һәм аермалы якларны анализлый, лексиканың тәрҗемә ителешен детальләп сурәтли.

Безнең әлеге хезмәтебез «Алмачуар» әсәрен тәрҗемә иткәндәге шәхси тәҗрибәбезне сурәтләп бирү белән, ягъни гамәли юнәлештә булуы ягыннан аерылып тора. Тикшеренү эшебездә анализ, күзәтү, чагыштыру, компонентлы анализ методлары һәм алымнары ярдәм итте.

## Фикер алышу

Г. Ибраһимовның «Алмачуар» повесте 1922 елда языла һәм татар халкының тормыш тәҗрибәсен, дөньяга карашын, гореф-

гадәтләрен, әхлак нормаларын һәм бай фольклор мирасын чагылдыра [27]. Әлеге әсәрне төрек теленә тәрҗемә иткәндә туган авырлыклар, әлбәттә, әсәрнең 1917 елга кадәрге татар авылының көндәлек тормышын, авыл халкының җир һәм ат белән мәш килүен, татар халкының милли бәйрәме булган Сабантуй бәйрәмен яктыртуына бәйле (Бу турыда тулырак: [14], [28], [29], [30], [31]). Татар һәм төрек авыл тормышының күп кенә охшаш яклары булса да, Сабантуй, мәсәлән, бары тик татар халкына хас бәйрәм һәм әсәрдә ул бик бай этнографик элементлар белән бирелә. Бер авыл малаеның тууын дүрт күз белән көтеп алган колынга булган мәхәббәтен аңлаткан әсәрне тәрҗемә иткәндә барлыкка килгән авырлыкларның күбесе нәкъ менә ат белән, аның исеме, төсләре, ат асрау, ат җигү өчен кирәк-яраклар белән бәйле булды.

Тәрҗемә эшенә алынгач та, әсәрнең исемен ничек тәрҗемә итү проблемасы килеп чыкты, чөнки төрек телендә *алмачуар* сүзе юк, бу төс бер сүз белән генә бирелми, атлар өчен мондый исем бөтенләй кулланылмый. Шактый уйланганнан соң, әсәрнең исемен үзгәртмичә калдырып, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән [32, 80 б.] бу төр ат төсенең төрекчә ачыкламасын бирүне уңай күрдек: «Almaçuar: Açık renkli lekeleri olan boz veya koyu kırmızı ile sarı arasında bir renkteki at donu» [15, 20 б.]. Шулай ук әсәрне тәрҗемә иткәндә, иң зур авырлык *туры бурлы, кара бурлы, бурлы, җирән* кебек ат төсләрен тәрҗемә иткәндә килеп чыкты. Алар бу рәвештә аңлатылды: *туры бурлы* ‘hardala çalan’, *кара бурлы* ‘siyah üzerinde tane tane beyaz tüyleri olan’, *бурлы* ‘siyah üzerinde parça parça beyaz tüyleri ya da beyaz üzerinde parça parça siyah tüyleri olan at donu’, *җирән* ‘kırmızımsı donlu’ [15, 20, 24, 27, 50 б.].

Тәрҗемә барышында ат җигү, ат тәрбияләү өчен кулланыла торган әйберләрнең һәм күренешләрнең, атның тән төзелешен белдергән атамаларның төрекчә яңгырашын табу өчен дә шактый көч куелды. Мәсәлән, *нукта* ‘yular’, *аркан* ‘kemend’, *тышаулау* ‘dizginlemek’, *тезген* ‘dizgin’, *тәртә* ‘arabanın kenarı’, *җигәргә өйрәтте* ‘hamut giymeyi öğretti’, *җикмибез* ‘koşup yormuyorduk’, *улак* ‘yem kabı, yemek oluğu’, *апара суы* ‘unlu su’, *маңгай чәче* ‘perçem’, *бәкәлләре* ‘kaval kemikleri’, *кашка* ‘sakar’ һ.б.

Әсәрдә авыл баласы Закирның атына булган мәхәббәте татарларның милли бәйрәме Сабантуй белән үрелеп бара. Хәтта әсәр бер Сабантуй вакыйгалары белән башлана, икенчесе белән бетә, дияргә мөмкин. Әлбәттә, тәрҗемә иткәндә, Сабантуй бәйрәмен дә ачыкларга кирәк иде: «*Sabantoy: Kazan Tatarlarında bahar mevsiminde ekin işleri bittikten sonra kutladıkları çift sürme bayramı*». Гомумән, әдәби әсәрләрне тәрҗемә иткәндә, милли бәйрәмнәрне, йолаларны, музыка коралларын, киемнәрне татар телендәге исеме белән калдырып, ачыклык кертү – иң дөрес карар дип уйларга җирлек бар. *Аулак өй* кебек татарларга хас күренешне дә төрек укучыларына ачыкларга кирәк. Чөнки Төркиядә аулак өй йоласы беркайчан да булмаган, кызлар белән егетләрнең бер урынга килүе тыелган. Аулак өйгә бирелгән аңлатма: «*Büyüklerin olmadığı eve oturmaya geldiğinde*». Сабантуйдан тыш, повестьта *Покрау бәйрәме* дә телгә алына. Аны да ачыкладык: «*Pokrov: Hıristiyan takviminde yer alan bir bayramın adı*».

Автор татар халкының телендә нык таралган һәм киң файдаланыла торган мәкаль һәм әйтемнәрне шактый күп куллана. Элекке буын кешеләренең зур тормыш тәҗрибәсе нәтиҗәсендә тупланган, халкыбызның йолаларын, язылмаган кагыйдәләрен яктырткан, тирән фикерне образлы һәм тапкыр итеп бирә торган мәкальләр әсәрдә әйтемнәргә караганда азрак очрый. Аларның кайберләре төрек укучысына нәкъ татарчадагы варианты белән дә аңлашыла, шуңа күрә сүзгә-сүз тәрҗемә ителде: *«Күңел – әүлия»* ‘Gönül, evliya’, *«Нәфес – шайтан»* ‘Nefis şeytanmış’, *«Тарыны йомшакка чәчсәң, чүп басып харап итә»* ‘Darıyı yumuşak toprağa saçarsan ot basıp harap eder’, *«Гөлләр чәнечкесез булмый»* ‘Dikensiz gül olmaz’, ә кайберләренең төрекчәдә эквивалентлары бар иде. Мәсәлән, *«Мин бер атуда ике куянны алмак булам»* ‘Ben bir taşla iki kuş vurmaya çalışıyordum’ (Мин бер таш белән ике кошка атырга тырыша идем).

Әсәр әйтемнәргә һәм фразеологизмнарга аеруча бай. Аларның күбесе төрек теленә төгәл тәрҗемә ителде. Мәсәлән, *тәңкә-тәңкә* ‘pul pul’, *таштан су чыгар, усак агачы алма бирер, ди, әбүҗәһел иманга килер* ‘taştan su çıkar, kavak ağacı elma verir, ebu cehil imana gelir’, *хафизга кем чыдасын!* ‘Hafız’a kim dayanır!’, *асыл сөяк чабышкы ат* ‘asilzade koşu atı’, *йөзе кара көйгән* ‘yüzü kararmış’, *көн чаба, төн чаба* ‘gece gündüz koşturdu’, *күз яшьләрен сөртә-сөртә* ‘gözyaşlarını silerek’, *муены камыт күрмәгән* ‘boynu hamut görmeyen’, *көткән*

*көннәр якынлыйлар* ‘beklenen gün yaklaştı’, *мыек астыннан көлеп* ‘bıyık altından gülümseyip’, *бармак белән санап барам* ‘parmakla sayıyorum’, *күз-колак була торырга кирәк* ‘göz kulak olmam gerek’, *бүген-иртәгә* ‘bugün yarın’, *аңардан күземне ала алмый* ‘gözlerimi onun üzerinden ayıramazken’, *колагымнан тартты* ‘kulağımı çekip’, *күземә йокы керми* ‘gözüme uyku girmedi’, *ни күрим!* ‘ne göreyim!’, *ярым шелтә, ярым шаяру белән* ‘yarı kızgın yarı neşeli bir şekilde’, *башымнан сыйпый* ‘başımı sıvazlıyor’, *карап туйгысыз* ‘bakmaya doyulmayacak kadar’, *канатланып оча* ‘kanatlanıp uçardı’, *асты өскә килә* ‘altı üstüne geldi’, *дөнья минеке иде* ‘dünyalar benim oldu!’, *көн буена аягым кая басканны белмим* ‘gün içinde ayağımın nereye bastığının farkına varmıyorum’, *үрти-үчекли башладылар* ‘dalga geçmeye başladılar’, *авыз тулы көенчә* ‘ağızım yemek doluyken’, *килеп җитте* ‘geldi çattı’, *таң-хәйранга калдылар* ‘şaşırıp hayran kaldılar’, *шик юк* ‘şüphesiz’, *ашамый-нитми* ‘bir şey yiyip içmeden’, *ыңгырашып ятты* ‘ıhlayarak yattı’, *ашавыннан-эчүеннән калды* ‘yemeden içmeden kesildi’, *йөрәгем таш булып катты* ‘kalbim taş kesilmişti’, *күз алдым караңгыланды* ‘gözüm karardı’, *телем томлыкты* ‘dilim tutuldu’, *тыя-тыя* ‘sakinleştirerek’, *сүзеннән кайтмый* ‘sözünden dönmezdi’, *бер сүз белән туктата* ‘tek bir sözle susturuyor’, *уйнаклап йөриләр* ‘oynamaya başladılar’.

Әлбәттә, әйтемнәрнең дә, фразеологизмнарның да күбесе өчен төрек телендәге эквивалентларын кулланырга мәҗбүр булдык. Мәсәлән, *бу эш хәерлегә булмас* ‘bu işte bir iş var’ (бу эштә бер эш бар), *карап катканнар* ‘gözünü ayırmadı’ (күзен аермады), *әкият итеп сөйләргә калды* ‘dillerde destan olarak kaldı’ (телләрдә дастан булып калды), *ни булса шул булыр* ‘oluruna varır’ (булачакка барыр), *аты-чабы чыгу белән генә калмады* ‘dillere düşmekle kalmadı’ (телгә төшү белән генә калмады), *дөнья җимереп* ‘bütün gücüyle’ (бөтен көче белән), *хәлле чак* ‘bolluk zamanı’ (барлык заманы), *башыма утырткан* ‘aklıma koymuştum’ (акылыма куйган идем), *мактанып беткән идем* ‘hava atmaya başlamıştım’ (һава ата башлаган идем), *шатлыгымнан кая сикерергә урын тапмыйм* ‘sevinçten dünyalar benim oluyor!’ (сөенечтән дөньялар минем булды), *башкаларның да күзләре кыза* ‘diğerleri de hemen gaza geldi’ (башкалары да коткыга бирелде), *миңа алары кыйбат түгел* ‘benim umurumda bile değildi’ (мин борчылмыйм), *аяк атламады* ‘ayak basmadı‘ (аяк басмады), *төшегезгә дә кермәгәндер* ‘rüyanızda bile görmemişsinizdir’ (төшегездә дә күрмәгәнсездер), *тыннарын да алмыйча* ‘nefesini tutup’ (сулышын тотып), *этлеккә генә түгел, яхшы сүзгә дә синең акылың, телең җитә икән* ‘aklın ve dilin sadece itliğe değil, iyi söze de yatkınmış’ (акылың һәм телең этлеккә генә түгел, яхшы сүзгә дә ята икән), *дога кылалар* ‘dua ettiler’ (дога иттеләр), *кырт кисә* ‘kestirip atardı’ (кистереп ата иде), *исән-сау* ‘sağ salim’ (сау-сәламәт), *күземә ак-кара күренмәде* ‘gözüm kararmıştı’ (күз алдым караңгыланды), *ат җене кагылган* ‘at cini çarpmış’ (ат җене бәргән), *бик кыйбат төшкән чаклар* ‘çok pahalıya patladığı zamanlar’ (бик кыйбатка шартлаган заманнар), *сүзем булмый, телем киселә* ‘susuyorum, dilim tutuluyor’ (сүзсез калам, телем тотыла), *язганы шулдыр* ‘yazgım böyleymiş’ (язмышым болай икән), *әйтәсе дә юк* ‘söylemeye gerek var mı’ (әйтергә кирәк бармы), *ашауга бик назлы* ‘yemek seçerdi’ (ризык сайлый иде), *сүзендә торды* ‘sözünden dönmedi’ (сүзеннән кире кайтмады), *башсыз кыз* ‘dengesiz bir kız’ (холыксыз кыз), *сүз уңае саен* ‘söz açılınca’ (сүз ачылгач), *йөрәген миңа баглаган* ‘gönlünü bana bağlamış’ (күңелен миңа баглаган), *хәтеремә килгәч* ‘aklıma gelince’ (акылыма килгәч), *күрергә язган булсын* ‘görmek nasip olsun’ (күрергә насыйп булсын), *аллы-гөлле* ‘allı pullu’ (аллы-тәңкәле), *күз тимәсен* ‘nazar değmesin’ («күз» сүзе урынына төрек телендә гарәпчәдән кергән «nazar» сүзе ешрак кулланыла), *көмеш тавыш белән* ‘gür bir sesle’ (көчле тавыш белән), *каттым* ‘dondum kaldım’ (катып калдым), *култыгына алды* ‘koluma girdi’ (кулыма керде), *җылак малай* ‘huysuz çocuk seni!’ (ah сине, көйсез бала!), *шатлыгым йөрәгемнән тулып таша* ‘sevinçten içim içime sığmıyor’ (сөенечтән эчем эчемә сыймый), *көн-төн карый* ‘gece gündüz demeden’ (төн-көн димичә), *эчем бора* ‘midem bulandı’ (ашказаным болганды), *өйлә намазына азан әйтергә* ‘öğle ezanını okumak için’ (өйлә азанын уку өчен), *дөньядан үтте* ‘dünyadan göçtü’ (дөньядан күчте), *күңелем дә, күзем дә төшмәде* ‘ne gözüm ne de gönlüm düştü’ (ни күзем, ни күңелем төште), *бәхетсез булды* ‘günyüzü göremedikleri gibi’ (көн йөзе күрә алмаганнары кебек), *аякка бастырды* ‘durumunu düzeltti’ (хәлен төзәтте), *мин кая басканымны белмим* ‘dünyalar benim oldu!’ (дөньялар минем булды!), *адәм көлкесенә калдырган* ‘rezil etmiş’ (хур иткән), *череп*

*беткән кара бай, кара черегән бай* ‘Karun kadar zengin adam’ (Харун кебек бай кеше), *дөнья гизгән* ‘güngörmüş’ (көн күргән), *бар белгәнең шул булды* ‘kalkınca aynı laf, yatınca aynı laf’ (уянса да шул ук сүз, яткач та шул ук сүз), *Ну, малай, эт икәнсең!* ‘aferin sana!’ (афәрин сиңа!), *гөнаһ шомлыгы* ‘kahrolası’ (каһәр буласы), *бертуктаусыз кайный* ‘telaş içinde’ (кабалану эчендә), *карт-коры* ‘köyün ihtiyarları’ (авыл картлары), *күңелем тынычланмый* ‘içim daraldı’ (эчем таралды), *сабан-сука күрмәгән бер җир* ‘hiç ekilmemiş bir tarla’ (бөтенләй игелмәгән җир), *Ни бар?* ‘Hayırdır?’ (Хәердер?), *фу, илаһым* ‘aman Allah’ım’ (аман, Аллаһым), *йөрәгенә авыр була* ‘zoruna gidiyordu’ (авырга китә), *тагы авыр хәл* ‘içim yandı’ (эчем янды), *ни күрсәң, үзең күрерсең* ‘ne olacaksa senden olsun’ (ни булса да синнән булсын), *йөзне хур итмәдең* ‘yüzümüzü kara çıkarmadın’ (йөзебезне каралтмадың), *бирер үзеңә дә кирәгеңне* ‘görürsün gününü’ (күрерсең көнеңне), *юкка* ‘boşu boşuna’ (бушка), *әллә нинди яшел тавыш белән чинап* ‘acayip sesler çıkartarak’ (гаҗәп тавышлар чыгарып), *ай үсәсен көн үсә* ‘gece büyüyor, gündüz büyüyor’ (төн үсә, көн үсә), *үземне-үзем белмәдем* ‘kendimden geçip’ (үз-үземнән үтеп), *минем бәхет җиңде* ‘şansım varmış’ (бәхетем бар икән), *рәхмәт укыйлар* ‘teşekkür edip’ (рәхмәт итеп), *тавык баш* ‘şaşkın çocuk’ (аптырашта калган бала).

Түбәндәге очракларда татар телендәге аерым сүзләр төрекчәдә башка мәгънәдә кулланылу сәбәпле, алар башка сүзләр белән тәрҗемә ителде: *рәхмәт укыйлар* ‘teşekkür edip’ (чөнки *rahmet* сүзе төрек телендә ‘Алла рәхмәтендә булсын’ мәгънәсендә кулланыла), *зур кайгы булып төште* ‘büyük bir dert çöktü’ (*kaygı* сүзе төрек телендә ‘борчу’ мәгънәсендә йөри), *баласының хәсрәтеннән* ‘çocuğunun üzüntüsünden’ (*hasret* сүзе төрек телендә ‘сагыну’ төшенчәсен бирә), *миннән дә яманрак* ‘benden beter’ (*yaman* сүзе төрек телендә куркусыз, батыр’ кебек уңай мәгънәләр аңлата), *бик зәһәре* ‘en iyisi’ (*zehir* сүзе төрек телендә ‘агу’ мәгънәсендә кулланыла).

Тәрҗемә эшен гыйбарәләрдәге бер үк фигыльләрнең татар һәм төрек телләрендә төрле мәгънәдә кулланылышы да авырайта: *зур кайгы булып төште* ‘büyük bir dert çöktü’ (*düşmek* сүзе төрекчә – ‘егылу’), *уйнап, ялкынланып торалар* ‘parildayip ateş saçıyordu‘ (төрек телендә *oynatak* –‘бию’), *терелеп* ‘iyileşip’ (*dirilmek* төрек телендә – ‘җан керү, терелү’), *курка төштем* ‘korku içinde’ (курку эчендә; чөнки *düştüm* сүзе төрек телендә ‘егылдым’ дигән мәгънәгә туры килә), *аяк чалды* ‘ayağına çelme taktı’ (төрек телендә *çaldı* – ‘урлады’), *колак салдым* ‘kulak kabarttım’ (*saltmak* сүзе төрек телендә башка мәгънәдә йөри), *аякка бастык* ‘ayağa kalktık’, (*bastmak* сүзе төрек телендә ‘өстенә басу’ны аңлата), *түшәккә дә егылдым* ‘yatağa düştüm’ (*yıkılmak* сүзе төрек телендә ‘беттем, харап булдым’ кебек мәгънәләр бирә).

«*Ходайның үз кулы белән, фәрештәләрнең ярдәме белән*» ‘Allah’ın eli ve meleklerin yardımıyla’, «*Йа Ходай!*» ‘Ya Rabbim!’ кебек татар әйтемнәрендәге фарсы сүзләренең төрек телендәге вариантларында гарәп сүзләре белән алыштырылганын күрергә мөмкин.

Әсәрдә чагыштырулар да бихисап. Аларның кайберсе бөтен төрки халыклар өчен уртак чагыштырулар: *китапка язган кебек сөйлисең* ‘kitaba yazılmış gibi konuşuyorsun’, *беләк юанлыгы* ‘bilek kadar’, *ут чыккан кебек* ‘bir yerde yangın varmışçasına’, *ана арыслан кебек* ‘dişi aslan gibi’, *кәбестә кочане кебек* ‘lahana gibi’, *язгы сабан өстендә йолыккан карга кебек* ‘bahar sabanı üzerinde gezinen tüysüz kargalar gibi’, *яшен кебек* ‘şimşek gibi’, *күз ачып йомганчы* ‘göz açıp kapatıncaya kadar’, *Әйтерсең, мәхшәр көне!* ‘Mahşer günüydü sanki!’. Кайберләрендә төрек телендә исемнәр аз гына үзгәрә: *имән кебек таза, лачын кебек үткен, арыслан кебек гайрәтле* ‘meşe gibi sıhhatli, kartal gibi keskin bakışlı, aslan gibi güçlü kuvvetli’ (лачын/kartal), *әкияттәге баһадир кебек* ‘destan bahadırları gibi’ (әкият/destan), *башыма нидер сукты* ‘kafamda sanki şimşekler çaktı’ (әйтерсең лә башымда яшеннәр яшьнәде), *үзеннән-үзе очарга барган* ‘kendi nefeslerinin kuvvetiyle uçup gitmeye hazır olan’ (үз сулышларының куәте белән очып китәргә әзер булган).

“*Рус боярларының матур кызлары кебек*” дигән чагыштыруда “бояр” сүзен ачыкларга туры килде: ‘Rus boyarlarının güzel kızlarına benziyordu’ ‘Boyar: Rus asilzade’. Ләкин икенче мәртәбә шул ук сүз кулланылган чагыштыруда инде “бояр” сүзе ачыкланмыйча бирелде: *кунакка барырга ясанган бояр җегете кебек* ‘misafirliğe gitmeye hazırlanan yakışıklı genç bir Rus boyara benzedi’.

Ачлыкны белдергәндә, татарча *эттән яман ачыкканмын* дигән чагыштыру, төрекчә ‘kurt gibi açtım’ (бүре кебек ачыкканмын) дип тәрҗемә ителә. Татар телендә бер егетнең төз гәүдәле булуын белдерү өчен кулланылган

*сөлек кебек* дигән чагыштыру төрек теленә ‘sülün gibi’ дип, кыргавыл/фазан кошы белән чагыштырылып бирелә. Ә менә “*Бура кебек таза, калын булып симерде*” дигән җөмләдәге *бура* белән чагыштыруны төрек теленә берничек тә ачыклап булмады, чөнки төрекләр өйләрен бурадан салмый. Шуңа күрә ‘bayağı bir semirdi’ (шактый симерде) дип кенә калдырдык.

Әсәрдә алкыш һәм каргыш кебек фольклор жанрлары да очрый. Аларны тәрҗемә иткәндә дә, төрек телендәге эквивалентлар белән бирдек: *Җиңел аягы белән килгән булсын!* ‘Uğurlu ayağıyla gelsin!’ (*uğurlu* – бәхетле), *Каһәр төшкән* ‘Lânet olası’ (ләгънәт буласы). Кайбер алкышларның татарча һәм төрекчә вариантлары туры килә иде: *Бәрәкәт китерсен!* ‘Bereket getirsin! ’.

Кайбер сүз төркемнәренең тәрҗемәсенә дә берникадәр ачыклык кертик.

Исемнәргә килгәндә, ягымлы итеп әйтелгән сүзләрне бирү авырлык тудырды. Мәсәлән, *картым* ‘kocacığım’, *бичаракаем* ‘zavallım’, *малкаем* ‘malcağızım’ һ.б. «Фатиха» сүзе дә төрек телендә бары тик Коръәндәге сүрә исеме буларак кулланылган өчен «фатиха бирү» мәгънәсендә ‘hayır dua’ буларак тәрҗемә ителде.

Алда искә алынган ат кушаматы «Алмачуар»ны тәрҗемә иткән кебек, елга, үзән һ.б. ялгызлык исемнәр дә төп нөсхәдәгечә, бары тик төрек теле кагыйдәләренә туры китереп, фонетик үзгәрешләр кертеп (транслитерация юлы белән) бирелде: *Кондызлы күл* ‘Kunduzlu göl’, *Үзән елгасы* ‘Üzen nehri’, *Өршәк* ‘Örşek’, *Өзән* ‘Özen’, *Дим* ‘Dim’, *Агыйдел* ‘Akidil’. Ләкин «Әчтерхан» шәһәре исемен татарча әйтелеше белән бирелгәнгә күрә, бераз ачыклык кертергә туры килде: «Eçtérhan: Rusya Hazar gölü kıyısında bulunan Astrahan şehri». Шул ук урында «Әчтерхан диңгезе» турында сүз барганда да, төгәллек кертү зарури булды, чөнки бирекдә сүз Хәзәр диңгезе (күле) турында бара: «Eçterhan denizi: Hazar gölü».

Әсәрдә балык төрләре атамалары да искә алына. Аларның кайберләренең язылышы һәм укылышы татар һәм төрек телләрендә уртак булса да (кызылканатлар – kızılkanatlar, сазан – sazan), кайберләренең төрек телендә үз вариантлары бар. Мәсәлән, *чуртан* ‘turna balığı’, *шукә* ‘turna balığı’, *алабугалар* ‘perki balıkları’, *чабак* ‘kefal’. Үлән төрләренә килгәндә дә, шул ук мәсьәлә: *кузгалак* ‘kuzukulağı’, *җир җиләге* ‘çilek’ кебек сүзләр бер төрле әйтелсә дә, төрекләрдә *кура җиләге* ‘böğürtlen’, *карлыган* ‘Frenk üzümü’, *чикләвек* ‘fındık’ буларак бирелә.

Татар халкына хас милли киемнәрдән әсәрдә *түбәтәй, кызыл киҗеле күлмәк, яулык* кебек берәмлекләр очрый. Аларны тәрҗемәдә түбәндәгечә бирдек. *Түбәтәй* сүзенә аңлатма китерелде. “*Tübetey: Tatar erkeklerine özgü bir çeşit millî şapka*». *Кызыл киҗеле күлмәк* ‘kırmızı, ince pamuk ipten dokunan gömlek’ буларак турыдан-туры тәрҗемә ителде. *Яулык* өчен төрек телендә кулланылган ‘yazma’ һәм ‘başörtüsü’ сүзләре кулланылды.

Татар халкының тормышында әһәмиятле урын алган милли кыйммәтләрдән *кызыл башлы сөлге* ‘kırmızı nakışlı havlu’ дип тәрҗемә ителде, *гармун* сүзен исә ачыкларга туры килде “*Garmun: Akordeona benzer bir müzik aleti*”.

Физик үзенчәлекләрне белдергән сыйфатларның да эквивалентларын төрек телендә турыдан-туры тәрҗемә белән түгел, ә әдәби һәм халык телендә киң таралган формада бирергә кирәк булды: *матур, зур* ‘boylu poslu iri yarı’, *зур, таза, баһадир, сылу* ‘cüsseli, sıhhatli, güçlü’, *ябык, чандыр* ‘sıska’ һ.б.

Кайбер төсләр төрек телендә татарчадагы кебек варианты булса да, башкача кулланыла: *ак сакал* ‘kır sakal’ (*kır* сүзе төрек телендә чәч һәм сакалны тасвирлаганда кулланыла. *Ак* сүзе төрек телендә булса да, *ак* дип әйтелми), *кап-кара* – ‘esmer’ (сүзгә-сүз тәрҗемәсе ‘simsiyah’ булса да, тәннең каралыгы төрек телендә гарәп теленнән кергән ‘esmer’ сүзе белән бирелә).

Вакыт өлешләрен тәрҗемә итүдә дә кайчак кыенлыклар килеп чыкты. Мәсәлән, *кояш төшлеккә җиткәнче* гыйбарәсе сүзгә-сүз тәрҗемә ителмәде, ‘akşama kadar’ (кичкә кадәр) дип тәрҗемә ителде. *Көн матур* сүзтезмәсендәге *көн* төшенчәсе төрек телендә *һава* сүзе белән бирелә ‘hava güzeldi’. *Өченче көн*’не дә төрек теленә ‘üçüncü gün’ дип күчерү ялгыш булыр иде, бу вакыт берәмлеге ‘evvelki gün’ дип бирелә.

Фигыльләренең күбесе татар теленнән төрек теленә нәкъ шулай тәрҗемә ителсә дә (*фәкыйрьлектә калабыз – iyice fakirleştik, сабыр итик – sabredelim, мин үлгәч чакырырсың – ben ölünce çağırırsın, догасы кабул булды – duası kabul oldu, йорт-җирне байтак төзәтте – evi avluyu da epey düzene koydu, мәхрүм итте – mahrum etti, кар эри башлагач та – kar erimeye başlayınca, кешниләр – kişniyorlar*), кайберләрен тәрҗемә итүдә үзенчәлекләр бар иде: *айгырдан чаптырыр – çiftleştirir, бөгәргә тотындым – hızlıca yemeye başladım, сукрана – söyleniyor,*

*мине җиңде – beni düşüncemden vazgeçirdi, каптырдык – balık tuttuk, ябышып чыкты – kaçtı, каплаган алган – çöktüş, катык оеп җитмәгән – yoğurt hazır değilmiş*. Күп очракта аларны төрек телендәге вариантлар белән бирергә туры килде: *кызгандым – göze alamadım, хәрәмләде – haksızlık yaptı, аркасыннан кага – sırtını sıvazlayıp, иркәләп – başını okşayıp, күкрәгем кысып-кысып ала – göğsüm sıkışıyor, йөрәгем суга – kalbim küt küt atıyor, таралалар – evlerinin yolunu tuttu, тыңламастан – kulak asmayıp, хәтергә алмады – hiçe saydı, үзенекендә тора – inat etmeye devam etti, сакларга – göz önünden ayırmamak*.

Әсәрдә сабан туенда көрәш һәм ат чабышы күренешләрен тасвирлаган җөмләләрдә хәрәкәт фигыльләрен тәрҗемә итү шулай ук авыр булды. Мәсәлән, *селтәп җибәрә – üzerinden firlattı, аз-маз шаярта да чөеп үк ташлый – biraz oynatıp sonra sırtüstü yere atıyordu, тәгәрәп-тәгәрәп китә дә чалкан барып төшә – yuvarlanıp yüzükoyun yere düştü, өстеңә йомылып килә – üstüne yürüyordu, каулама – gaza getirme, кире чигенә – geri geri gidiyor*.

Тәрҗемә эшен кайвакыт Г. Ибраһимовның әсәрдә җирле сөйләм лексикасы кулланылуы да берникадәр авырайтты. Чөнки аларны башта татар һәм башкорт телләренең диалекталь сүзлекләреннән эзләп табып, аңлатмаларын белергә кирәк иде. Мәсәлән, *яту* сүзен башкорт теленең диалекталь сүзлегеннән [33, 526 б.] тәрҗемәнең редакторы эзләп тапты һәм аны төрек телендә ‘girdap’ дип бирдек.

Әлбәттә, повестьта татар теленнән төрекчәгә тәрҗемә иткәндә, сүзгә-сүз охшаш берәмлекләр дә бихисап күп иде. Мәсәлән, *ат* (at), *тай* (tay), *колын* (kulun), *хәер-дога* (hayır dua), *чапан* (çapan), *билбау* (bel bağı), *мәсхәрә* (maskara), *күк* (gök), *мәлгун* (melun), *һайди*! (haydi!) һ.б. Хәтта төрекчәгә бермә-бер шулай тәрҗемә ителгән җөмләләр дә аз булмады: *Әткәйгә барып сыенам, иркәләнәм* – Babama sokulup dert yanıyordum, *Кояш түбәнәеп бара* – Güneş batıyor.

Тәрҗемәләре табылган аваз һәм образ ияртемнәре: *йөрәгем жу-у итеп китте – yüreğim hop etti, чыж-пыж итеп – cızbız*. Кайберләре исә төрле юллар белән тәрҗемә ителде: *пырых-пырых итеп – değişik bir ses çıkararak* (әллә нинди бер тавыш чыгарып). Ләкин бөтенләй тәрҗемә ителмәслек авыр сүзләр дә бар иде. Мәсәлән, *агакай, лырт-лырт, төш ауган* һ.б. Аларны сүзгә-сүз тәрҗемә итеп булмады.

**Төп нәтиҗәләр**

Алда язылганнардан чыгып, шундый фикергә килергә була: әдәби әсәрне татар теленнән төрек теленә тәрҗемә иткәндә, аны төрек телен яхшы өйрәнгән татар кешесе генә тәрҗемә итә алмый. Тәрҗемә итсә дә, ул әсәр төрек укучысына үз телендә язылган әсәрләр кебек аңлашылмаска мөмкин. Бу очракта ана теле татар теле булган тәрҗемәче, һич шөбһәсез, ана теле төрек теле булган, әдәби төрек телен бик яхшы белгән шәхестән ярдәм алырга тиеш. Шуңа күрә Төркиянең Могъла университетында эшләгән елларда, төгәлрәк әйткәндә 2008 елда, Гаяз Исхакыйның хикәяләрен төрек теленә төрек галиме Хаяти Йылмаз белән бергә тәрҗемә иттек [8]. Соңгырак елларда Марсель Гариповның Тукай белән Зәйтүнә Мәүлүдованың мәхәббәтен сурәтләгән «Мәңгелек мәхәббәт» романы тәрҗемәсен дә Хаяти Йылмаз белән бергә башкардык [9]. 2020 елда Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» повестен төрек теленә инде ялгыз тәрҗемә иткән булсак та, редактор буларак, төрек галимен билгеләдек [10]. Үткән ел Галимҗан Ибраһимовның хикәяләрен төрек теленә янә ялгыз тәрҗемә иттек һәм тагын редактор буларак, төрек галимен билгеләүне уңай күрдек. Бу китапның редакторы итеп, Могъла университетыннан укучым, инде үзе дә хәзер Афьон университетында татар теле һәм әдәбияты белгече булып эшләүче, Роза Туфитуллованың Гөлсем Камалова турында язган романын татар теленнән төрек теленә тәрҗемә иткән яшь галимә Гөлшах Йылмазны [11] билгеләдек. Мәкаль һәм әйтемнәрне төрек теленә күчергәндә һәм, гомумән, әсәрнең мөмкин кадәр төрек укучысына якын, яратып укыла торган әсәр булуы өчен аннан бик күп ярдәм алдык. Төрек галимнәре Фәүзия Бәйрәмованың «Чыңгыз Айтматовның татар анасы» хезмәтен [12] һәм Әлфия Ситдыйкованың «Дөнья тәгәрмәче» исемле әсәрен [13] татарчадан төрекчәгә тәрҗемә иткәндә, аларның редакторы булуын сөенеп кабул иттек һәм тәрҗемәләрнең мөмкин кадәр төгәл булуы өчен көч куйдык.

Танылган тәрҗемә белгече, галим Р.А. Юсупов хаклы рәвештә билдергәнчә, һәртөрле тәрҗемәгә куелган иң әһәмиятле, хәлиткеч таләп шуннан гыйбарәт: ул тәрҗемә ителә торган материалның (оригиналның) эчтәлеген, мәгънәсен дөрес телдә, мөмкин булганча тулы итеп бирергә тиеш [34, 4 б.].

Шушы хакыйкатьне истә тоткан хәлдә, без төрле ысул-алымнар кулланып, «Алмачуар» әсәрен төрек укучысы яратып, аңлап, үз итеп кабул итәрлек дәрәҗәдә тәрҗемә итәргә тырыштык.

Йомгак ясап әйткәндә, матур әдәбият әсәрләре башка төр текстлардан структурасы белән дә, эчтәлеге белән дә нык аерылып тора. Аларда теге яки бу халыкка гына хас үзенчәлекле лексика, милли колорит чагыла. Реалияләр, фразеологизмнар, мәкаль-әйтемнәр текстны тагын да тулы, бай, тәэсирле итә. Аларны тәрҗемә итү юллары да төрле: сүзгә-сүз тәрҗемә, эквивалент белән алыштыру, төшереп калдыру яки өстәү һ.б. Татар телендәге текстны төрек теленә тәрҗемәсе белән чагыштырып караганда, әлеге текстларның охшаш булуын, ягъни лексик берәмлекләрнең тулысынча диярлек тәрҗемә ителгәнен күрергә була. Эквиваленты булмаган очракта да, эчтәлеккә зыян салмыйча гына, лексик берәмлекне теге яки бу сүз белән алыштырып яки аңлатып бирдек. Шул рәвешле тулы кыйммәтле тәрҗемә тудырырга тырыштык. Хәер, безнең хезмәтебезгә ахыргы бәяне киләчәктә укучы бирер.

**Әдәбият**


1. Ğıylecev A. Bir Avuç Toprak / Гыйләҗев А. Өч аршин җир) / тәрҗ. Ф. Котлы. Әнкара: «Бәнгү» нәшр., 2013. 113 б.
2. Muhammedi R. Sirat Köprüsü. İstanbul, 2017. 554 s.
3. Ğıylecev A. Cuma günü, akşam… / Гыйләҗев А. «Җомга көн, кич белән...» / тәрҗ. Ф. Котлы. Анкара «Бәнгү» нәшр., 2013. 202 б.
4. Vasiyet / "Васыять": повесть һәм хикәяләр җыентыгы / тәрҗ. Ф. Котлы, Һ. Әрсой-Надир, Т. Арслан. Истамбул: «Замбак» нәшр., 2012. 111 б.
5. Batulla R. Cengaver Alp'in Kahramanlıkları. Ankara, Bengü Yayınları, 2013, 152 s.
6. Zeydulla R. Beyaz Hırkalı İhtiyar. Ankara, Bengü Yayınları, 2016, 112 s
7. Нуртдинова Г.М., Тахтарова С.С., Хабибуллина Э.К. Татарское литературное наследие в аспекте перевода // Полилингвиальность и транскультурные практики. 2021. Т. 18. № 3. С. 442–450.
8. İshaki A. Hikâyeler (Seçmeler). Çev. Çulpan Zaripova Çetin-Hayati Yılmaz. Muğla, Muğla Üniversitesi Yayınları, 2009. 182 s.
9. Garipov M. Ebedi Aşk. Abdullah Tukay ile Zeytüne Mevlüdova Hikâyesi. Çev. Çulpan Zaripova Çetin-Hayati Yılmaz. Ankara: Bengü, 2016. 103 s.
10. Çulpan Zaripova Çetin. İbrahimov A. Ademler. Araştırma-İnceleme-Metin. Ankara: Bengü, 2020. 170 s.
11. Tufitullova R. Gülsüm. Çev. Gülşah Yılmaz. Ankara: Bengü Yayınları, 2020. 174 s.
12. Bayramova F. ANA. Cengiz Aytmatov'un Anne Şeceresi. Çev. Bülent Bayram- Duygu Dudi Ertem. Ankara: Bengü, 2019. 182 s.
13. Alp Eren Demirkaya. Elfiye Sitdıykova. Dünya Tekerleği. İnceleme-Metin. İstanbul: Ihlamur Kitap: 2023. 152 s.
14. Садекова А.Х. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова. Казан, ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АН РТ, 1995. 105 с.
15. İbrahimov A. Seçme Eserler. Çev. Çulpan Zaripova Çetin. Ankara: Bengü, 2022. 290 s.
16. Халит Г. Галимҗан Ибраһимов (Тормышы һәм иҗаты). Кереш мәкалә // Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. 3 томда. 1 том. Казан, 1957. 527 б.
17. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов. Казан, 1969, 431 б.
18. Надиров И. Традиционные образы татарской народной лирики // Развитие гуманитарных наук в Татарии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. С.130-139.
19. Ханнанов Р. Төрек-татар әдәби бәйләнешлары (Турецко-татарские литературные связи) // Казан утлары. 2011. № 2. Б.78-83
20. Сайфулина Ф.С. Татарско-турецкие культурные и научные взаимосвязи: история и современность // Филология и культура. Philology and Culture. 2014. №2 (36). С.322–326.
21. Хабибуллина Э.К. Языковые трансформации при переводе татарской литературы на турецкий язык: дис. ... канд. филол.н. Казань: КФУ, 2016. 283 с.
22. Сайфулина Ф.С., Валиева А.З. Фатих Котлу как переводчик и пропагандист татарской литературы в Турции // Tatarica. 2019. №2. 27–52 б.
23. Хабибуллина Э. К. Замены как грамматические трансформации, используемые при переводе татарской художественной прозы на турецкий язык // Гуманитарные, социально-экономические и общественные науки. 2015. № 11/2. С. 265–268.
24. Хабибуллина Э. К. Особенности грамматических трансформаций при переводе произведений татарской литературы на турецкий язык // Прикладные аспекты сопоставительной лингвистики: обучение иностранному языку с опорой на родной язык: (материалы II Международной науч.-практ. конф., проводимой в рамках IV Международного научнопрактического форума «Сохранение и развитие языков и культур», КФУ. Казань, 2015. С. 107–110.
25. Хабибуллина Э.К., Юсупова А.Ш. Грамматические замены как вид трансформаций при переводе современной татарской прозы на турецкий язык // Tatarica. 2019. №2. 31–54 б.
26. Аслан Б.О., Хайретдинова Р.Р., Озчобан Й, Садекова А.Х. Татарская литература в Турции: особенности бытования и изучения // Tatarica. 2019. №2. 27–52 б.

27. Ибраһимов Г. Алмачуар // Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. Казан: ТаРИХ, 2002. Б.218–242. // URL: https://kitaphane.tatarstan.ru/tat/ibr_book1.htm?ysclid=lny0518boy495807527 (мөрәҗәгәть итү вакыты 12.09.2023).

28. Хабутдинова М.М. «Ранняя весна» детской литературы (Г. Ибрагимов) // Идель. 2005. №4. С. 56–59.

29. Хабутдинова М.М. Национальная идентичность и ее отражение в сознании ребенка (на материале рассказа Г. Ибрагимова «Алмачуар» («Чубарый»)) // Мировая словесность для детей и о детях. М.: МПГУ, 2008. С.120–124.

30. Zaripova Çetin, Çulpan. Alimcan İbrahimov'un Eserlerinde Tatar, Başkurt ve Kazak Türklerinin Kültürel Değerleri. Ankara, Bengü: 2016. 384 s.

31. Bayrakdarlar T. Review of the Monograph of Ch. Zaripova-Cetin "Cultural Values of the Tatar, Bashkir and Kazakh People in the Works of Galimzyan Ibragimov" (Çetin, Çulpan Zaripova (2016), Alimcan İbrahimov'un eserlerinde tatar, başkurt ve kazak türklerinin kültürel değerleri, Ankara: Bengü Yayınları, 369 s., ISBN: 978-605-9148-42-9.) // Tatarica. 2018. №1 (10). S. 176–181.

32. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. I том: А–В. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 712 б.

33. «Ятыу» Хәҙерге башкорт әҙәби теленең аңлатмалы һүҙлеге. Өфө, Рәсәй Фәндәр академияһы Өфө фәнни үҙәгенең Тарих, тел һәм әҙәбиәт институты, 2004. 528 б.

34. Юсупов Р.А. Дөрес тәрҗемә итик. Казан, 2015. 216 б.

# ТРУДНОСТИ ПЕРЕВОДА: НА ПРИМЕРЕ ПЕРЕВОДА НА ТУРЕЦКИЙ ЯЗЫК ПОВЕСТИ ГАЛИМЖАНА ИБРАГИМОВА «ЧУБАРЫЙ»

**Чулпан Афраимовна Зарипова-Четин**,
Кавказский университет,
Turkey, 36000, Kars/Center,
chulpancetin@gmail.com.

**Раушания Сагдатзяновна Нурмухаметова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
rsagadat@yandex.ru.

В практике перевода выделяют переводы, выполненные между родственными и неродственными языками. Народы издавна интересовались чужой историей, культурой, литературой. Таким образом появились разные переводы.

В центре предлагаемой статьи ставятся родственные тюркские языки – татарский и турецкий. Несмотря на сходство лексики, грамматики этих языков, в переводе возникает достаточно много трудностей.

Этот труд посвящен описанию некоторых сложных случаев, возникших в процессе перевода татарского текста на турецкий язык. Сопоставительный анализ оригинала и перевода свидетельствует о том, что даже между родственными языками возникают переводческие трудности, возникают проблемы в процессе перевода лингвокультурных явлений, реалий, пословиц и т. д. Применение различных переводческих приемов и методов дает возможность успешного решения трудностей перевода. Авторы статьи подробно описывают трансформации при переводе на другой язык отдельных лексических единиц, связанных с особенностями жизни и быта татарского народа, а также сцены Сабантуя в произведении Г. Ибрагимова «Алмачуар». Таким образом, создается научно-практическое представление о переводе с родственных языков.

**Ключевые слова:** родственные языки, татарский язык, турецкий язык, трудности перевода, перевод, эквиваленты, трансформации